СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №129 (7458) | 29 октябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

**ДУСЛЫК**

**Хөрмәтле укучылар!**

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**

◆ Бер колхоз хәбәрләре



## Кышны — яңа бинада

«КОНДЫРЧА» КОЛХОЗЫ. Быел хуҗалыкның товарлыклы сарыкчылык фермасы коллективы өчен олы сөенеч булды: яңа терлекчелек бинасы файдалануга тапшырылды. 400 башка исәпләнгән бу бинаны колхозның төзүчеләр бригадасы членнары Нурислам Ишниязов, Рифкать һәм Фәрит Әюповлар, Фәргать Гайнуллин төзеделәр.

Шулай итеп, быел маллар кышлатуга яңа биек, җылы бинага кайттылар. Анда терлекләрне асрау өчен бер уңайлы булса, терлекчеләргә эшләү өчен дә бөтен шартлар тудырылган.

Малларга җитәрлек азык хәзерләнүен дә әйтеп үтәсе килә. Димәк, кышлату чоры уңышлы узачак, үрчем һәм продукт алуда да зур кыенлыклар булмаячак.

Колхоз эшчәннәре кышны тулы куәтенә каршылыйлар.

x x x

## Ике очта — ике мәчет

Түбән Норлат авылында эшләп килгән ике — Ясаклы һәм колхоз ягы мәчетләренең һәр икесе яраклаштырылган бинага гына урнашкан иде. Авыл картлары киңәштеләр, уйлаштылар да һәр ике мәчетне дә яңартырга булдылар. Төзелеш эшләрендә Сәгыйть ага Ильмухин, Миннәхмәт ага Бакиров, Талип ага Әюпов башлап йөрүчеләрдән булдылар. Колхоз транспорты, башка кирәк-яраклары белән булышып торды. Хәзер төзелеш ахырына якынлашып килә, колхоз ягындагы мәчетнең түбәсе ябылды, икенчесендә нәкъ шул эш бара. Эш шундый темпта барса, картлар беренче намазны яңа биналарда укыр көннәргә дә күп калмаячак.

**Х. РӘХМӘТУЛЛИН.**

✦

Газ һәм электр белән эретеп ябыштыручы Азат Әхмәдиев машина төзү заводында озак еллардан бирле эшли. Үз һөнәренең остасы, бик дисциплиналы, һәр эшне сыйфатлы һәм күңелгә ятарлык итеп башкарырга гадәтләнгән Азатны цехта хезмәттәшләре дә хөрмәт итәләр. Алар нигездә КУТМ-60 һәм КУ-12 җайланмалары әзерлиләр. Инде хәзер, завод я чимал юклыктан, я җитештерелгән продукцияне реализацияләү авырлыгыннан кыенлык кичергәндә, алар җәйләрен еш кына район хуҗалыкларында килешү нигезендә эшләр башкарырга мәҗбүрләр. Азат биредә дә сынатмый, эшче маркасына тап төшерми.

Әхмәдиев — заводның профсоюз комитеты члены, әйбәт гаилә башлыгы һәм шулар өстенә эрудицияле, төпле фикерләүче, һәр яңалык белән кызыксынучы яшь кеше дә.



РӘСЕМДӘ: машина төзү заводының газ һәм электр белән эретеп ябыштыручысы А. Әхмәдиев.

## Курслар эшли

Эш сәгате тәмамлануга «Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең бер төркем белгечләре һәм хезмәткәрләре уку классына җыелалар. Махсус җиһазланган бүлмәдә алар гарәп алфавитын өйрәнәләр.

Бу дәресләрне Уфада мәдрәсә тәмамлаган, технологик транспорт идарәсенең дежур механигы Тәлгать Әхмәт улы Могайнетдинов алып бара.

Әлеге курсларга татар милләтеннән булган тыңлаучылар йөри. Ноябрь аеннан биредә, идарә хезмәткәрләре, эшләүчеләр теләген исәпкә алып, татар теленә өйрәтү курслары да эшли башлаячак. Бу группага рус һәм башка милләт вәкилләре язылды.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**

● Кискен сигнал

## «Борчылганнар»

Соңгы вакытта районда сөт җитештерүнең түбәнәюе һәркемне борчуга салырлык, аерым хуҗалыкларда (мәсәлән, «Алга»да) ул хәтта 3 килограммга (!) кадәр төште. Хәл сөт җитештерүчеләрнең үзләрен дә «борчыган» күрәмсең, һәм алар тиз генә төзәтеп тә ташларга ниятләгәннәр. Ничек итепме? Бик җиңел һәм бик тиз ысулны тапканнар — сөткә... су кушканнар. Әйе, әйе, нәтиҗәдә савым да арткандыр, тик менә сөтнең тыгызлыгы гына бар нәрсәне фаш итеп ташлаган. 27 октябрь көнне «Мамык» совхозының 2 нче фермасыннан килгән сөтнең тыгызлыгы куб см.га 1026,8 граммга тигез иде. «Игенче», «Знамя Октября», Муса Җәлил исемендәге колхозлардан куб. сантиметрына 1025,7 граммдагы сөт китерелде. Сөт арттыруның бу ысулы, шулай итеп, колхозларга бер дә файда китерә алмады.

Шул ук вакытта сөтнең пычраклылыгы да канәгатьсезлек уята. «Знамя Октября», «Алга», «40 лет Победы» колхозлары, «Төрнәс», «Сөлчә» совхозлары бу көнне чисталыгы буенча III класслы сөт китереп, болай да аз продукцияне тагы да дәрәҗәсезгә калдырдылар.

Ел ахыры җитә, һәркем аны уңышлы тәмамлар өчен бар резервларны барларга тиеш, югыйсә. Ә бездә әле һаман я күз буяу, я битарафлык. Моңа кайчан чик куелыр икән?

## Былтыргыдан артык

«Россия» колхозы терлекчеләре агымдагы елның тугыз аенда һәр сыердан уртача 2898 килограмм сөт савып алдылар. Бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 144 килограммга артыграк. Билгеле, аерым группаларда бу күрсәткечләр тагы да югарырак. Менә, Валентина Наумова ел башыннан бирле һәр сыердан уртача 3537 килограмм, ә аның кулдашы Ольга Перепелкина исә 9 айда һәр сыердан уртача 3261 килограмм сауды. Мария Имукова да алардан азга гына калыша. Аның күрсәткечләре һәр сыерга 9 айда 3111 килограмм тәшкил итте.

**М. МИХЕЕВА,**
экономист.

■ Игътибар: яңалык

## «Орион» тәкъдим итә

Карл Маркс урамының 3 катлы йортларының иң яңасы, 29 номерлысы каршында пәйда булган ул язуга күпләр игътибар итәргә өлгергәннәрдер: «Орион» коммерция-комиссион кибете. Кайберәүләр мыек астыннан көлемсерәр: әһе, бездә шул гына юк иде, ниһаять, ул да ачылды, дияр. Ашыкмагыз. Иң әлек яңа фирма кибетен карап, аның киләчәккә планнары белән танышыйк.

Йортның подвал өлеше зәвык белән әйбәтләп ремонтланган, уңайлы витриналарда сатып алучылар күрерлек, караплык итеп товарлар тезелгән. Сатучы Эльмира Шәйдуллина аларны һич иренмичә алып та күрсәтергә әзер. Нәрсәләрме? Күп төрле товар: бижутерия, галантерия товарларыннан алып өс, аяк киемнәре, ашамлык әйберләренә кадәр бар.

Каян килгән соң ул товарлар кибеткә, гомумән, бу яңа кибет нинди нигездә ачылган? Болары хакында безгә «Орион» ширкәте директоры — запастагы офицер Дамир Краснов сөйли:

— Ширкәт әлегә дүрт учредитель һәм бер сатучы составында эшли. Безнең төп максатыбыз — халык арасында ихтыяҗ зур булган товар әйләнешен тәэмин итү, икенче төрле әйткәндә, без — арадашчы ролендә: кемдә товар артык — аңардан аны сатып алу, кемгә кирәк — аңа сату. Кибет тулысы белән халыктан сатып алынган, китерелгән товарлар хисабына яшәячәк. Фирманың бернинди спонсоры юк, без җылылык челтәреннән бары бина гына арендага алып торабыз. Киләчәктә исә биредә машиналар өчен запас частьләр бүлеге ачарга җыенабыз, иркен холлда балалар кафетерийсы оештырырга уйлыйбыз.

Әлегә кибетнең яшәү срогы бик кыска: ул 22 октябрьдә генә ачылды. Беренче көннәр нәтиҗәләре үк кибет хезмәтеннән файдаланырга теләүчеләрнең байтак булачагына өметләндерә.

— Көненә 25—30 меңлек товар сатылды, — ди Эльмира. Шуңа дәлил: хәзер дә «Орион» буш түгел. Әллә гел сатып алырга теләүчеләр генә миндә? Юк, менә әйбер тапшырырга теләүче дә бар икән. Дамир аңа товарны кабул итү шартын аңлата:

— Паспортыгыз бармы? Рәхим итеп, үз бәягезне куясыз. Шуны онытмагыз: әйбер бәясенең 10 проценты кибет файдасына тотыла.

Ике арада тиз генә килешү төзелә, ирләр курткасы бераздан витринага да эленә. Яңа клиент С. В. Абрамова икән. Кибет турында фикерен иренмичә бүлешә.



— Мин мондый кибет не кирәк дип саныйм. Бездә бит һәрберебездә базарда басып сату итү сәләте юк, аңа күңел дә бармый. Дөнья бит: кемдәдер артык әйбер ята, икенче берәү аны дөнья бетереп эзли. Бу кибет нәкъ аларны очраштырырга тиеш дип уйлыйм.

Кибеткә керүчеләр өзелми. Берәүләр нидер эзли, икенчеләр бәлки кызыксынып кына керәдер. Әмма анда булгач, соңгыларының да уйланулары ихтимал: чү, миндә дә артык әйберләр юкмы, бәлки кемдер аны тилмереп эзлидер? Һәр ике категория кешеләр өчен дә «Орион» үз хезмәтен тәкъдим итә.

Рәхим итегез!

**С. НУРУЛЛИНА.**

